Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-3**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында

1995 елның 23 ноябрендәге “Экологик экспертиза турында”гы 174-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ номерлы Федераль законарга, Әйләнә-тирә- мохитне саклау буенча Россия Федерациясе Дәүләт комитетының 2000 елның 16 маендагы “Россия Федерациясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башкаэшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү хакында Нигезләмәне раслаутурында”гы 372 номерлы боерыгына туры китереп,Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (теркәлә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның
4 сентябрендәге XXXIII-3
номерлы карары беләнрасланды

Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмә

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.Әлеге Нигезләмә 1995 елның 23 ноябрендәге “Экологик экспертиза турында”гы 174-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ номерлы Федераль законарга, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы территориясендә экологик экспертиза узарга тиешлекүздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгатьчелек тыңлаулары формасында җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибен (алга таба – тәртип) гамәлгә кертә.

2.Күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгатьчелек тыңлаулары формасында җәмәгатьчелек фикер алышулары (алга таба – җәмәгатьчелек тыңлаулары) һәркемнең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә һәм аның торышы хакында дөрес мәгълүматка конституцион хокукын тормышка ашыру максатларында,шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларына кагыла торган карарлар кабул итүдә гражданнарның катнашуы максатларында үткәрелә,

3.Җәмәгатьчелек фикер алышулары инициаторы тарафыннанҗәмәгатьчелек фикер алышуларынҗәмәгатьчелек тыңлаулары формасында үткәрү турында карар кабул ителгән очракта1995 елның 23 ноябрендәге “Экологик экспертиза турында”174-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендәдәүләт экологик экспертизасы объектлары җәмәгатьчелек тыңлауларыначыгарыла.

## 2.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турында карар

4.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турында карар Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннанТатарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты постановлениесе (карары) формасында кабул ителә.

5.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турындагы карарда күрсәтелә:
-җәмәгатьчелек тыңлауларының темасы;
-җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

-күздә тотылган эшчәнлекнең исеме, максаты һәм урнашу урыны;
-инициаторның атамасы һәм адресы (заказ бирүченең яки аның вәкиленең);
-җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрүнең якынча сроклары;
- җәмәгатьчелек тыңлауларын оештыруга җаваплы орган;
-фикер һәм тәкъдимнәрне кабул итү тәртибе һәм сроклары;
-күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек материаллары белән танышу срогы һәм урыны.

6.Экологик экспертиза узарга тиешлекүздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгатьчелек тыңлауларынТатарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнеңәйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү буенча җәмәгатьчелек тыңлаулары формасында җәмәгатьчелек фикер алышуларын үткәрүгә тәгаенләнгән эшче төркем оештыра һәм үткәрә (алга таба – җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем)..

Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркемнең составы Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

7.Җәмәгатьчелек тыңлауларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны җәмәгатьчелек тыңлаулары инициаторы күтәрә.

8.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турындагы хәбәрне массакүләм мәгълүмат чараларында җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү датасына чаклы 30 көннән дә соңга калмыйча игълан итүне тәэмин итә.

9.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрүнең Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге халкына тыңлауларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итү вакытыннан алып җәмәгатьчелек тыңлаулары йомгаклары турында нәтиҗәне игълан итүгә кадәрге срогы бер айдан артык була алмый.

10. Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турында хәбәр формасында булырга тиеш:

-җәмәгатьчелек тыңлауларының темасы;
-җәмәгатьчелек тыңлаулары үткәрүнең датасы, вакыты, урыны;
-күздә тотылган эшчәнлекнең исеме, максаты һәм урнашу урыны;
-инициаторның атамасы һәм адресы (заказ бирүченең яки аның вәкиленең);
-җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрүнең якынча сроклары;
-җәмәгатьчелек тыңлауларын оештыруга җаваплы орган;
-фикер һәм тәкъдимнәрне кабул итү тәртибе һәм сроклары;
-күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек материаллары белән танышу срогы һәм урыны.
-башка мәгълүмат.

11.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем компетенциясенә керә:

1)җәмәгатьчелек тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү буенча эш планы төзү;

2)җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителгән материалларга анализ ясау;

3)кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерү һәм җәмәгатьчелек тыңлауларында фикер алышуга чыгарылучы конкрет мәсьәләләр исемлеген ачыклау;

4)җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашуга экспертлар сыйфатында чакырылучы вазыйфаи затлар, белгечләр,оешмалар һәм башка җәмәгатьчелек вәкилләренең исемлеген аныклау һәм аларга фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләр буенча үзләренең тәкъдимнәрен җиткерү үтенече белән рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

5)чакырылган затлар составын да кертеп җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучы затлар исемлеген төзү;

6)докладчыларны билгеләү;

7)җәмәгатьчелек тыңлауларында чыгыш ясауларның тәртибен һәм эзлеклелеген раслау;

8)җәмәгатьчелек тыңлауларының беркетмәсен алып бару;

9) ) җәмәгатьчелек тыңлаулары йомгаклары буенча нәтиҗә чыгару;

10)әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә башка мәсьәләләр.

## 3.Җәмәгатьчелек тыңлауларыныңинициаторлары

12.Җәмәгатьчелек тыңлауларыныңинициаторлары булып дәүләт экологик экспертизасы объектлары проектларының заказ бирүчеләре тора.

13.Җәмәгатьчелек тыңлауларыныңинициаторлары:

1)җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрүне оештыру-техник һәм мәгълүмат ягыннан тәэмин итәләр;

2)җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турындагы хәбәрнеҗәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 30 көн алданмассакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыруны тәэмин итәләр.

Әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне бәяләү буенча материалларның баштагы вариантына керү урыны һәм сроклары, җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү урыны һәм датасы, җәмәгатьчелек катнашуының башка формалары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтындаҗәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү тәмамланганчы алдан 30 көннән дә соңга калмыйча игълан ителә.

Заказ бирүче шулай ук әлеге мәгълүматны күздә тотылган эшчәнлек тормышка ашкан сурәттә турыдан-туры яки читләтеп аның мәнфәгатьләренә кагылырга ихтимал булган кызыксынучыяки тәэсирне бәяләү процессына үзенең кызыксынуын күрсәткән җәмәгатьчелеккәһәм әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне бәяләү процессының күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чараларына керергә (танышырга) мөмкинлеге булмаган башка катнашучыларына җиткерә.

Җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларга өстәмә хәбәр ирештерү әлеге Нигезләмәнең 13 пункты 2 пунктчасында ишарә ителгән мәгълүмат таратуныңрадио, телевидение, вакытлы матбугат, Интернет юлы белән һәм мәгълүмат таратуны тәэмин итүче башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3) дәүләт экологик экспертизасы объекты проектларын,шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне бәяләү буенча материалларның баштагы вариантын җәмәгатьчелеккә танышу һәм әлеге Нигезләмәнең 13 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән хәбәр игълан ителгән көннән алып 30 көн дәвамында, әмма җәмәгатьчелек тыңлаулары тәмамланганчы 2 атнадан да соңга калмыйча фикерләрне тапшыру өчен тәкъдим итүне тәэмин итәләр.

14.Җәмәгатьчелек тыңлауларын билгеләү турында карар кабул итү өчен инициаторлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына күздә тотылган экологик экспертиза узарга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлек хакында җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турында үтенечне үз эченә алган,экологик экспертиза узарга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең төрен күрсәтеп, белдерү җибәрәләр.

Белдерүгә дәүләт экологик экспертизасы объекты проектлары турында мәгълүмат теркәлә.

## 4. Җәмәгатьчелек тыңлауларын хәзерләү

15. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетыҗәмәгатьчелек тыңлауларыныңинициаторы тарафыннан җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү турында үтенечтапшырылган көннән соң ундүрт көнлек срокта тәкъдим ителгән документларны карый һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгатьчелек тыңлауларын билгеләү турында постановление проектын хәзерли.

## 5.Җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларны теркәү

16.Җәмәгатьчелек тыңлаулары башланыр алдыннан җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар теркәлергә тиешле. Җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларны теркәүне җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем гамәлгә ашыра.

Җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларны теркәү җәмәгатьчелек тыңлаулары башланырга бер сәгать кала башлана.

17.Теркәлгәндә җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар – физик затлар шәхесне раслаучы документ күрсәтәләр. Юридик затлар вәкилләре теркәлгәндә юридик затны дәүләт теркәве турындагы таныклыкны, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документларны, аларның шәхесләрен раслаучы документларны күрсәтәләр.

18.18 яшькә җиткән физик затлар һәм юридик затлар, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 16, 17 пунктлары нигезендә җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар сыйфатында теркәлгән җәмәгать оешмаларыҗәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар була, шул исәптән:

- инициатор, заказ бирүче, инвестор, проект документациясен,әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итәргә мөмкин булган күздә тотылган эшчәнлекне нигезләүче материалларны һәм дәүләт экологик экспертизасын узарга тиешле башка документацияләрне эшләүче;

-дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары;

-күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик, социаль һәм икътисади нәтиҗәләренә ихтыяҗ белдергән җәмәгатьчелек:Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындаҗәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү көненә юридик хокуклы булган яшәүчеләр.

19.Җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларны теркәүҗәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларның исемлеген исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

20.Теркәлүне кире кагу рөхсәт ителә шул очракта, әгәр зат теркәү вакытында әлеге Нигезләмәнең 18 пунктында каралган документларны тәкъдим итмәсә яисә әлеге Нигезләмә нигезендә җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучы булып тормаса.

21.Теркәү узмаган затлар җәмәгатьчелек тыңлауларына үткәрелми.

## 6. Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү

22. Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе җәмәгатьчелек тыңлауларын ачып җибәрә,җәмәгатьчелек тыңлауларының темасын, җәмәгатьчелек тыңлауларына чыгарылучы мәсьәләләрнең исемлеген, җәмәгатьчелек тыңлауларында чыгышларның тәртибе һәм эзлеклелеге буенча эшче төркемнең тәкъдимнәрен укып чыга, җәмәгатьчелек тыңлауларының доклад ясаучысын игълан итә, җәмәгатьчелек тыңлауларының сәркатибе белән таныштыра..

23.Җәмәгатьчелек тыңлауларының сәркатибе җәмәгатьчелек тыңлауларының беркетмәсен алып бара.

Җәмәгатьчелек тыңлауларының беркетмәсендә җәмәгатьчелек тыңлауларының датасы һәм үткәрү урыны, җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларның тыңлауларда булучыларының саны,эшче төркем җитәкчесенең, урынбасарының, сәркатибенең, эшче төркемнең башка әгъзаларының, докладчының яки җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучы чыгыш ясаучының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, аларның доклады яки чыгышының кыскача эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар, башка әйберләр чагылдырыла.

Җәмәгатьчелек тыңлауларының беркетмәсе җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркемнең сәркатибе һәм җитәкчесе тарафыннан имзалана.

24.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркемнең җитәкчесе чират тәртибендә чыгыш ясар өчен сүзне төп докладчыга, чыгыш ясарга хокукы булган җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларга һәм чакырылган затларга бирә.

25.Һәрбер чыгыштан соң җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар теләсә кайсысы докладчыга сорау бирергә хаклы.

26.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе, чыгыш ясарга теләк белдерүчеләрнең санына бәйле рәвештә,җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларның чыгыш ясаучыларының теләсә кайсының чыгыш ясау вакытын чикләргә хаклы.

Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе җәмәгатьчелек тыңлауларында тәнәфес игълан итәргә хокуклы.

27.Чыгышлардан соң фикер алышулар оештыру өчен җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе фикер алышу үткәрелә торган сорауны игълан итә һәм сүзне үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясарга хокукы булган калган җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларга бирә.

Барлык чакырылган затлар да фәкать җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе рөхсәте белән генә чыгыш ясыйлар.

28.Чыгыш ясарга хокукы булган җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучының чыгышы төгәлләнгәннән яисә чыгыш ясау өчен бирелгән вакыт чыкканнан соң, җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесеҗәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларга чыгыш ясаучының позициясе һәм (яки) дәлилләре буенча аныклаучы сораулар җиткерергә мөмкинлек һәм сорауларга җавап бирү өчен өстәмә вакыт бирә. Сорауларга җавап бирү вакыты җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучының төп чыгышы вакытыннан артык булырга тиеш түгел.

29.Сораулар язмача бирелергә дә, шулай ук телдән бирелү формасында да булырга мөмкин.

Язмача формада бирелгән сораулар җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесенә тапшырыла һәм телдән бирелгән сорауларга җаваплардан соң алар яңгыратыла.

30.Җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркемгә үзләренең фикер һәм тәкъдимнәрен тиндәшле рәвештә җәмәгатьчелек тыңлаулары беркетмәсенә кертү өчен тапшырырга хаклы.

31.Чыгыш ясауга хокукы булган җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучы үзенең тәкъдимнәрен кире алырга һәм (яки)башка җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар тарафыннан китерелгән тәкъдимнәргә кушылырга хаклы. Карала торган мәсьәлә буенча үзләренең позицияләре үзгәрү турында җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучыларның карары җәмәгатьчелек тыңлаулары беркетмәсендә чагылдырыла.

32.Җәмәгатьчелек тыңлауларының һәрбер соравы буенча катнашучыларның чыгышлары тәмамланганнан соң җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе аларга үткәрелгән фикер алышу йомгаклары буенча аларның позицияләренең үзгәрү ихтималлыгы турындагы сорау белән мөрәҗәгать итә.

33.Җәмәгатьчелек тыңлаулары темасының барлык сораулары буенча фикер алышу төгәлләнгәннән соңҗәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем җитәкчесе җәмәгатьчелек тыңлаулары темасының барлык сораулары каралганнан соң йомгаклау документында калган тәкъдимнәрне аныклау өчен сүзне сәркатипкә бирә.

34. Теләкләре булган барлык җәмәгатьчелек тыңлауларында катнашучылар тарафыннан фикер алышу проектының асылы буенча үзләренең уй-фикерләре әйтеп бетерелгәннән соң җәмәгатьчелек тыңлаулары тәмам булды дип санала.

## 7. Җәмәгатьчелек тыңлауларының нәтиҗәләре

35.Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү йомгаклары буенча беркетмә төзелә.

36.Җәмәгатьчелек тыңлаулары беркетмәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

-кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны;

-эшче төркем тарафыннан кире кагылган сораулар саны;

-җәмәгатьчелек тыңлауларында чыгарылган, әмма кабул ителмәгән сораулар;

-җәмәгатьчелек тыңлауларында кабул ителгән сораулар.

Җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү беркетмәсе күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнеңәйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү буенча материалларның азаккы вариантына кушымталарның берсе сыйфатында керә.

37.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетыэшче төркем җитәкчесе тарафыннан расланган вакыттан алыпкалендарь көннәр белән исәпләнгән өч көнлек срокта җәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү беркетмәсенҗәмәгатьчелек тыңлауларын үткәрү инициаторына җибәрә.

38.Күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне тормышка ашыру турында карар кабул итүгә кадәрге чорда гражданнардан һәм җәмәгать оешмаларыннан язмача фикерләр һәм тәкъдимнәр кабул итү,күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен бәяләү буенча материалларга кушымталарда бу тәкъдимнәрне документлаштыруҗәмәгатьчелек тыңлаулары инициаторы (заказ бирүче) тарафыннан җәмәгатьчелек тыңлаулары тәгәлләнгәннән соң 30 көн дәвамында тәэмин ителә.